**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ V ЧАКЫРЫЛЫШ X СЕССИЯСЕ**

**КАРАР № 45**

Мөслим авылы 30 август 2026 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» Мөслим муниципаль районы Советының 2022 елның 14 декабрендәге 130 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» Мөслим муниципаль районы Советының 2022 елның 14 декабрендәге 130 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 19 статьяның 5 пунктындагы 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару территорияләре»;

1.2. 17 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«яисә рекреацион билгеләнештәге зоналарны билгеләү» сүзләрен «рекреацион билгеләнештәге зоналарны билгеләү яисә торак пункт чикләренең җир кишәрлекләре чикләре белән кисешүен бетерү» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе А.Р.Хуҗин